ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.10.2018 Казан ш. № 4-2/г

2019 елга Татарстан Республикасының газлаштыру программасын финанслау өчен «Газпром трансгаз Казан» Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең газ бүлү челтәрләре буенча газны транспортлау хезмәтләре тарифларына махсус өстәмә түләү размерларын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы 69-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Газлаштыру программаларын финанслау өчен газ бүлү оешмалары тарафыннан газны транспортлау тарифларына махсус өстәмә түләүне билгеләү тәртибе турында» 2001 елның 3 маендагы 335нче карары, Тарифлар буенча федераль хезмәтнең «Газлаштыру программаларын финанслау өчен газ бүлү оешмалары тарафыннан газны транспортлау тарифларына махсус өстәмә түләү размерларын билгеләү методикасын раслау турында» 2011 елның 21 июнендәге 154-э/4 номерлы боерыгына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 нче боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты БОЕРА:

1. 2019 елның 1 гыйнварыннан 2019 елга Татарстан Республикасының газлаштыру программасын финанслау өчен «Газпром трансгаз Казан» Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең газ бүлү челтәрләре буенча газны транспортлау хезмәтләре тарифларына махсус өстәмә түләү размерларын кулланучыларның барлык төркемнәре өчен (халыктан башка) әлеге карарга теркәлгән кушымтага ярашлы рәвештә билгеләргә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
2018 елның 5 октябрендәге 4-2/т номерлы
боерыгына кушымта

2019 елга календарь бүленеш белән Татарстан Республикасының газлаштыру программасын финанслау өчен «Газпром трансгаз Казан» Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең газ бүлү челтәрләре буенча газны транспортлау хезмәтләре тарифларына махсус өстәмә түләү размерлары

| Татарстан Республикасының газ бүлү оешмалары исемлеге | Ел | Махсус өстәмә түләү размеры, 1000 куб. метрга сумнарда (ӨКСны исәпкә алмыйча) |
| --- | --- | --- |
| «Газпром трансгаз Казан» Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | 2019 елның 1 гыйнварыннан алып 2019 елның 30 июненә кадәр | 59,34 |
| | 2019 елның 1 июленнән алып 2019 елның 31 декабренә кадәр | 61,18 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тарифларны кабул итүне оештыру, тикшерү һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге